# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

"Татарстан Республикасы законнарын һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы тарафыннан кабул ителгән башка актларны бастырып чыгару һәм гамәлгә кертү тәртибе турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

I. "Татарстан Республикасы законнарын һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның Президиумы тарафыннан кабул ителгән башка актларны бастырып чыгару һәм гамәлгә кертү тәртибе турында" Татарстан Республикасы Законына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 статья. 1 статьяда:

1 өлештә "Известия Татарстана" һәм "Татарстан хәбәрләре" дигән сүзләрне төшереп калдырырга, "Советская Татария" сүзләрен " Республика Татарстан" дигән сүзләр белән алмаштырырга;

2 өлештә "һәм аның Президиумы" дигән сүзләрне төшереп калдырырга.

2 статья. 2 статьяның 1 өлешендә "Известия Татарстана" һәм "Татарстан хәбәрләре" дигән сүзләрне төшереп калдырырга, "Советская Татария" дигән сүзләрне "Республика Татарстан" дигән сүзләр белән алмаштырырга.

34

3 статья. 3 статьяның 1 өлешендә "һәм аның Президиумы" дигән сүзләрне төшереп калдырырга.

4 статья. 4 статьяны төшереп калдырырга.

5 статья. 5 һәм 6 статьяларны 4 һәм 5 статьялар дип санарга.

6 статья. 5 статьяда "һәм башка актлар" дигән сүзләрне төшереп калдырырга.

П.7 статья. Әлеге Закон басылып чыккан көненнән гамәлгә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты М.Шәймиев

Казан шәһәре,
1995 елның 24 мае
№85